**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Алексеевск районының Сахаровка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасы Актаныш районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, иминлексезлек сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Алексеевск районының Сахаровка авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасы Актаныш районының Кәзкәй авылы янындагы «Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең («Тыңламас» бүлекчәсе) мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясендә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Алексеевск районының Сахаровка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасы Актаныш районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2020 елның 18 мартындагы ПУ-176 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 19 май
№ ПУ-295